ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык тугызынчы утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык тугызынчы утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 485-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).
2. «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 486-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).
3. «Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2024 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» 503-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
4. «Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруның аерым мәсьәләләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 501-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
5. «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 500-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
6. «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 502-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

7. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 505-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

8. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының $8^{1}$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 504-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

9. «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 488-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

10. «Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү турында» 479-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).

11. «Эскроу счетлардан файдаланып төзелеш подряды шартнамәләре буенча торак йортлар төзү турында» 471420-8 номерлы федераль закон проекты хакында (шәхси йортлар төзүдә һөнәри подрядчы оешмаларны проекттагы финанслау турында).

12. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына «Эскроу счетлардан файдаланып төзелеш подряды шартнамәләре буенча торак йортлар төзү турында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә үзгәрешләр кертү хакында» 471417-8 номерлы федераль закон проекты турында (шәхси йортлар төзүдә подрядчы оешмаларны проекттагы финанслауны кертүгә бәйле рәвештә законнарны камилләштерү хакында).

13. «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 149 статьясына үзгәреш кертү турында» 471415-8 номерлы федераль закон проекты хакында (подрядчы эшләрен өстәмә бәягә салым салудан азат итү турында).

14. «Пестицидлар һәм агрохимикатлар белән куркынычсыз эш итү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 471418-8 номерлы федераль закон проекты турында.

15. Хөкүмәт сәгате: «Россия Федерациясе Пенсия иминияте һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге эшчәнлеге турында».

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы Ю.З. Камалтынов

Казан шәһәре,
2023 елның 17 ноябре
№ 2228-VI ДС